РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АЛЬМЕТЬЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ӘЛМӘТ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«19» ноябрь 2024 ел г. Альметьевск № 3677

Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы, 2024 елның 22 июлендәге «Россия Федерациясе Җир кодексына үзгәрешләр кертү турында» 194-ФЗ номерлы федераль законнар нигезендә

БАШКАРМА КОМИТЕТ КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының кайбер карарларына:

- «Муниципаль милектәге җир кишәрлеген түләүсез бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 19 ноябрендәге 1643 номерлы (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 30 мартындагы 737 номерлы карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып);

- «Муниципаль милектә булган җир кишәрлеген милеккә, арендага, даими (вакыты чикләнмәгән) файдалануга, түләүсез файдалануга торглар үткәрмичә бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2021 елның 22 ноябрендәге 1667 номерлы карарына (Әлмәт муниципаль районы Башкарма комитетының 2022 елның 22 июлендәге 1547 номерлы, 2023 елның 10 апрелендәге 868 номерлы, 2023 елның 13 ноябрендәге 2041 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

карарның 1 нче кушымтасында:

- 2.8.2 бүлекчәсенең 2.8.2.1 пунктының 8), 9), 10 пунктчаларын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8) күрсәтелгән җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада территория чикләрендә урнашкан, аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә, моңа җир кишәрлеген бирү турындагы гариза белән әлеге җир кишәрлегендә

урнашкан бина, корылма, биналар милекчесе, төзелеш объекты яисә мондый җир кишәрлегенең хокук иясе мөрәҗәгать иткән очраклар керми;

9) күрсәтелгән җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада аңа карата башка зат белән территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән яисә аны комплекслы үстерү турында карар кабул ителгән территория чикләрендә урнашкан, әгәр күрсәтелгән карарны гамәлгә ашыру өчен территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзү таләп ителмәсә яисә җир кишәрлеге территорияне комплекслы үстерү турында башка зат белән килешү төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән булса, моңа карата мондый җир кишәрлеге федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен билгеләнгән һәм мондый җир кишәрлеген бирү турында гариза белән күрсәтелгән объектларны төзүгә вәкаләтле зат мөрәҗәгать иткән булса;

10) күрсәтелгән җир кишәрлеге җир кишәрлеген бирү турындагы гаризада үзләренә карата территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән җир кишәрлегеннән төзелгән һәм территорияне планлаштыру буенча расланган документлар нигезендә федераль әһәмияттәге объектларны, региональ әһәмияттәге объектларны яисә җирле әһәмияттәге объектларны урнаштыру өчен каралган, моңа җир кишәрлеген арендага бирү турындагы гариза белән әлеге затның күрсәтелгән объектларны төзү буенча йөкләмәсен күздә тоткан территорияне комплекслы үстерү турында шартнамә төзелгән зат мөрәҗәгать иткән очраклар керми;»;

2.10. бүлегенең исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.10. Муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган һәм 210-ФЗ номерлы Федераль законның 1 статьясындагы 1 өлешендә каралган дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүдә катнашучы оешмалар һәм Россия Федерациясе законнары нигезендә вәкаләтле экспертлар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеге».

2. Әлеге карарны «Альметьевский вестник» газетасында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (PRAVO.TATARSTAN.RU) урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны район Башкарма комитеты җитәкчесенең икътисад буенча урынбасары А.А. Ямалетдиновка йөкләргә.

Район Башкарма комитеты
җитәкчесе вазыйфаларын башкаручы — А. М. Каюмов